Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар комиссия тарафыннан бинаны карау турында карар чыгарганнан соң ике эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураның үтәлеше нәтиҗәләре булып комиссия әгъзаларына, мөрәҗәгать итүчегә һәм экспертларга карау датасы турында хәбәр итү тора.

3.5.5. Комиссия билгеләнгән көнне урынга чыга һәм экспертлар һәм мөрәҗәгать итүче катнашында бинаны тикшерә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча бинаны тикшерү акты төзелә.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнгән административ процедуралар бинаны карау көнендә башкарыла.

Административ процедураларның үтәлеше нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: бинаны тикшерү акты.

3.5.6. Комиссия секретаре бинаны карау актын комиссия каравына чыгара.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар бинаны тикшерү уздырганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларның үтәлеше нәтиҗәләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: комиссия каравына кертелгән бинаны тикшерү акты.

3.5.7. Комиссия үз утырышында:

торак урынын яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану турында гаризаны карый;

бинаның билгеләнгән таләпләргә туры килүенә бәяләү үткәрә;

әлеге Регламентның 2.8.1 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең булу-булмавын тикшерә;

бинаны карау һәм бинаны тикшерү актын рәсмиләштерү кирәклеген билгели.

Кирәк булмаган очракта, комиссия торак бинаны яшәү өчен яраклы дип тану (танымау) турында карар кабул итә. Карар беркетмәгә кертелә.

Бинаны карау һәм бинаны тикшерү актын рәсмиләштерү зарурилыгы булган очракта, комиссия әгъзалары әлеге Регламентның 3.5.5 – 3.5.6 пунктларында каралган процедураларны башкара. Торакны яшәү өчен яраклы дип тану (танымау) мөмкинлеге турында карар акт рәсмиләштерелгәннән соң кабул ителә.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнә торган административ процедуралар утырыш көнендә башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: торак бинаны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану турында карар.

3.5.8. Комиссия секретаре комиссия карарын бәяләмә рәвешендә рәсмиләштерә (3 нөсхә) һәм комиссия әгъзаларына имзалау өчен тапшыра.

Административ процедураларның үтәлеше нәтиҗәләре булып имзага тапшырылган бәяләмә тора.

3.5.9. Комиссия әгъзалары бәяләмәне имзалыйлар һәм секретарьга җибәрәләр.

